**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «15» декабреннән № 513

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү кыйммәтенең нормативларын раслау һәм 12 сәгатьлек эш режимы белән сак постлары санын билгеләү турында

«Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү һәм 12 сәгатьлек эш режимы белән саклау постлары санын билгеләү турында» 2021 елның 24 ноябрендәге 1114 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү бәясен өченче куркынычлык категориясе буенча – бер сак постына 130 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының бер белем бирү оешмасында 12 сәгатьлек эш режимы белән сак постлары санын өченче куркынычлык категориясе буенча - 1 саклау посты урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә

муниципаль районы сайтында (http://www.novosheshminsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларының өченче куркынычлык категориясенә караган объектлары (территорияләре) өчен террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтүнең нормативы нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов